| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

27.12.2016 № 1577-п

2017елда халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләренә тарифлар турында.

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясы нигезендә һәм «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 17 декабрендәге 941 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2017 елның 1 гыйнварыннан һәм 2017 елның 1 июленнән торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен торак урынны карап тоткан һәм ремонтлаган өчен түләү күләмен һәм торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан һәм ремонтлаган өчен түләү күләмен расларга һәм гамәлгә кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. «2017 елда халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләре тарифлары турында» Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 16 декабрендәге 1541-п номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Саба таңнары» район газетасында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад бүлеге башлыгы М.Р. Ишниязовка йөкләргә.

Р.М. Гасимов